Кукмара муниципаль районы
Янил авыл җирлеге Советы

КАРАР

15 март 2021 ел № 4

«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахитов авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2020 елның 01 декабрендәге 1 номерлы Вахитов торак пункты җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахитов авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Янил авыл җирлеге Уставының 22 ст. нигезендә Янил авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2021 нче елның 26 мартына 10 сәгать 00 минутка «Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахитов авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2020 елның 01 декабрендәге 1 номерлы Вахитов торак пункты җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 1 нче этабын билгеләргә. Халык җыенын Вахитов авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә: Вахитов авылы, Клуб урамы, 12 йорт.

2. 2021 нче елның 26 мартына 13 сәгать 00 минутка «Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахитов авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2020 елның 01 декабрендәге 1 номерлы Вахитов торак пункты җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 2 нче этабын билгеләргә. Халык җыенын Вахитов авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә: Вахитов авылы, Клуб урамы, 12 йорт.

3. 2021 нче елның 26 мартына 15 сәгать 00 минутка «Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахитов авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2020 елның 01 декабрендәге 1 номерлы Вахитов торак пункты җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 3 нче этабын билгеләргә. Халык җыенын Вахитов авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә: Вахитов авылы, Клуб урамы, 12 йорт.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахитов авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2020 елның 01 декабрендәге 1 номерлы Вахитов торак пункты җыены карарына түбәндәге эчтәлекле 4 нче абзацны өстәү юлы белән үзгәрешләр кертергә сез ризамы:

«- Әфганстанда булган сугышчы-интернационалистларга һәйкәл төзү, мемориаль такта; проект-смета документларын төзү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча түләү;»

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Янил авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Янил авыл җирлеге башлыгы: И. Х. Корбанов

ОГРН 1021607753310
ИНН 1623001893